СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2026 г. Агрыз № 9-4

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2025 елның 24 июнендәге 47-4 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын раслау хакында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карар чыгарды:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2025 елның 24 июнендәге 47-4 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 нче бүлектә:

а) 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда белешмәләрне тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.»;

б) 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне

тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча белешмәләр тапшырырга тиеш.»;

в) 3 нче пунктта «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 нче пунктта «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 5 пунктта «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга,»;

е) 6 пунктта «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга,»;

ж) 7 пунктта «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга,»;

з) 11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәискә) тапшыра.»;

и) 12 нче пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

к) 14 нче пунктта «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 19 бүлекнең 3 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр»;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев